СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

2 апрель, 1997 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 36 (8048) | Бәясе билгеләнгәнчә

# 30 мартта районыбызда Татарстан Дәүләт Советына депутат сайлау булды

## Тавыш бирү йомгаклары

1997 елның 30 мартында 50 нче Октябрь административ - территориаль сайлау округыннан Татарстан Республикасы халык депутатын сайлау уздырылды.

Тавыш бирү исемлегенә 39732 сайлаучы кертелгән иде. Тавыш бирүдә 38680 сайлаучы (исемлектәгеләрнең 97,4 проценты) катнашты. 38406 сайлаучы (тавыш бирүдә катнашканнарның 99,3 проценты) депутатлыкка кандидат Ф.С.Сибагатуллинны яклап, 274 сайлаучы аңа каршы тавыш бирде.

Округ сайлау комиссиясе.

## ЫШАНЫЧЫГЫЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ

Кадерле иптәшләр!

Хөрмәтле сайлаучылар!

Җаваплы сайлау алды чоры минем өчен депутатлыкка кандидат буларак чиксез зур куаныч белән тәмамланды. Сайлаулар нәтиҗәләре күрсәткәнчә, октябрьлеләрнең 97,4 проценты сайлауда катнашып, шуларның 99,3 проценты Республика Дәүләт Советына депутат итеп минем кандидатурамны яклап тавыш бирде. Бу - сезнең, хөрмәтле иптәшләр, миңа булган ышанычыгыздан тыш районда барган икътисадый - социаль үзгәрешләрне чын йөрәктән хуплавыгызны, киләчәктә иңгә - иң куеп янәшә эшләргә әзер булуыгызны да дәлилләде.

Республика парламентында вәкил булу, район халкының мәнфәгатьләрен чагылдыру, алдан ук әйткәнемчә, минем өчен зур мәртәбә, ә анда сезнең тулы ышанычлы фатихагыз белән аяк басу - икеләтә дәрәҗәле шатлык. Шуңа да бүген мине 50 нче административ - территориаль сайлау округыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәткән «Норлат шикәр заводы» акционерлык җәмгыяте коллективына, сайлау алды кампаниясендә минем программамны, уй - ниятләремне халыкка җиткерүдә булышкан иптәшләргә, миңа ышаныч күрсәтеп тавыш биргән сайлаучыларга ихлас рәхмәтемне белдерәм. Үз чиратымда, бар белемемне, тәҗрибәмне сезнең ышанычны аклауга, эшлекле активлык белән республика парламентында районның лаеклы вәкиле булырга, югары вәкаләт мөмкинлекләрен район мәнфәгатьләрен яклауга, сайлау алды платформамда билгеләнгән киң колачлы үзгәртеп корууларны гамәлгә ашыруга эшкә җигәргә тырышачакмын. Сезнең һәрдаим ышанычыгызны, ихтирамлы хуплавыгызны тою миңа яңа омтылыш, энергия белән эшләргә көч бирер.

Сезгә тагы бер кат рәхмәтемне җиткереп, иминлек, исәнлек, уртак җиңү куанычлары телим.

Ф.СИБАГАТУЛЛИН,
халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе, район хакимияте башлыгы.

## НАМУС КУШКАНЧА

Алдан фаразлангана, 30 мартта сайлау частокларында тавыш ирү активлык белән узы. Шәһәр халкының ртән бик иртә кузгалавын гына аңларга буа инде аның. Тик аны ы озакка бармады: əгать 10 га Норлаттаы сайлаучыларның 9,3 роценты гына тавыш иргән булса, көн уртаында бу күрсәткеч ине 37,3, ә сәгать 2гә 0,9 процентка җитте...

Участокларда бик тыыч булды. Сайлау бюлетеньнәрен сайлаучызе сораган телдә бирεләр. Гадәттәгечә, беенче булып өлкән шьтәгеләр тавыш бире. Куйбышев участоында пенсионер Гайиннар, тимер юл участыгында пенсионер Любовь Андреевна Ореина, Шашинда - 80 шьлек Əминә Гаяз кыы Гайфетдинова, Заод округында Миңнеуй Ярулла кызы Исхаэва һәм аның улы Раик, пенсионер Зоя лексеевна Федорова ң беренче булып илгәннәр.

Билгеле инде, 510 нчы частокта сайлауның ничек барышы белән аерым кызыксындык. Ник дисәң дә, нәкъ шул территориядәге «Норлат шикәр заводы» АҖе коллективы Фатих Сәүбән улы Сибагатуллинны Татарстан Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтте бит. Сайлау комиссиясе рәисе Людмила Николаевна Соколованың бу эштә тәҗрибәсе зур һәм шуңа күрә чагыштырып карар мөмкинлеге дә җитәрлек.

- Безнең участок районда иң зурысы, ди ул. - Исемлектә 3200дән күбрәк сайлаучы. Тавыш бирү ипле, эшлекле төстә бара. Сайлаучыларыбыз көннең икенче яртысында активлашалар - кем авылдан кайта, кем кайдан... Ә инде килгәннәре районыбызның киләчәге хакына, күзгә күренердәй үзгәрешләрне хуплап тавыш биреп киттеләр. Хәзер бит халык фәкать конкрет эш - гамәлләрдән генә чыгып фикер йөртә. Ул яктан, пенсияләрне айдан - айга китерәләр, ярты елда чиркәүнең эшен бетерделәр, яңа автобус маршрутлары ачылды, газ кертү тизләште... Шулай булгач ничек инде кандидатыбызны яклап тавыш бирмисең ди?..





Н.Азизов фотолары.

(Ахыры 2 нче биттә).

***«Дуслык», («Дружба», «Туслах») район газетасы коллективы 10 меңле укучылары исеменнән район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинны Татарстан Дәүләт Советы депутаты итеп сайлануы белән ихлас котлый һәм аңа район халкы мәнфәгатьләре хакына нәтиҗәле, эшлекле хезмәт, иҗат уңышлары, сәламәтлек тели.***

*Матбугат - 97*

## «Дуслык»ка льготалы язылу!

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

1 апрельдән элемтә бүлекләренә килеп, матбугат басмаларына язылганда без Сезнең иң беренче бланкларны «Дуслык»ка дип тутырачагыгызга шикләнмибез. Шунысын да әйтик, редакция, район элемтә узелы белән килешеп, район газетасына ярты елга язылу бәясен элеккечә, ягъни 23.400 сум көенә калдырды. Бу хакта үзегез күргән - белгәннәрнең моңарчы безнең газетаны алдырмаганнарына да җиткерерсез дип уйлыйбыз.

**Һәм, иң мөһиме!**

**Апрельнең 1еннән 10сына кадәр «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газеталарына льготалы бәягә, ягъни 16.200 сумга гына язылып калырга мөмкин.**

**Атнасына өч көн чыга торган матбугат органына язылуның шуннан да арзанрак бәясенең әле беркайда да булганы юк. Шулай булгач, нибары 16.200 сум акчагызны кызганмыйча, район газетасына язылып куйсагыз, ел ахырына кадәр райондагы хәлләр турында хәбәрдар булып торачагыгыз көн кебек ачык - анысына без ышандырабыз.**

**Дус булыйк, «Дуслык»лы булыйк!**

## Газ - көтелгән кунак ул

*Башланган эш - беткән эш*

**Биккол кебек гомер - гомергә ягулыкка тилмергән далалы як кешеләре өчен - бигрәк тә. Шуңа 29 март көнне авыл уртасында газ бүлү пунктында авылга зәңгәр ягулык килүен белдереп факел кабызу тантанасына һәркем чиксез шатлык белән җыелды.**

Тантанада чыгыш ясаучы һәркем - халык депутатлары район Советы рәисе урынбасары Е.К.Савинов та, район хакимиятенең аппарат җитәкчесе Ф.М.Галимов та, «Норлатгаз» эксплуатация - производство идарәсе начальнигы В.В.Богатиков та, «Таң» кооперативлар ассоциациясе рәисе Ә.С.Шәрәфетдинов та газ кертүне авылның социаль проблемаларының иң өлгергәне дип атап, аның хәл ителүен халык өчен зур шатлык дип бәяләделәр. Газ үткәрүдә подрядчылар - Димитровград шәһәренең 14 нче МСУсы бригадасы адресына да җылы сүзләр яңгырады. Авыл халкының район җитәкчелегенә, газчыларга рәхмәтен авылның мөхтәрәм кешесе Габделәхәт ага Бильданов җиткерде, тиз арада өйләрдә дә зәңгәр ялкын кабынасына өметен белдерде. Анысын озак көтәргә туры килмәячәк. Авыл эчендә эшне 14 нче МСУ бригадасы белән бергә «Норлатгаз» эксплуатация - производство идарәсе эшчеләре алып бара. Хәзердән 18 йорт зәңгәр утны кабызырга тулысынча әзер. Газчыларның исәбе - авыл кешеләренә ягулык шатлыгын мөмкин кадәр тизрәк бирү, шуңа да алар эш темпын киметмиләр. Ә халык исә бу сөенечле вакыйганы районда башланган позитив үзгәрешләрнең нәтиҗәсе дип кабул итте, аның, ниһаять, Бикколга да килеп җитүенә куанып, яхшыга өмет белән таралды.

## Рәсми хроника

### Управляющий сайланды

31 март көнне «Сельхозтехника» акционерлык җәмгыяте әгъзаларының гомуми җыелышы булды. Җыелыш шәхси гаризасы нигезендә управляющий Андрей Тихонович Воронцовны вазифаларыннан азат итте. Берләшмә управляющие итеп моңарчы «Норлат машина төзү заводы» акционерлык җәмгыяте баш инженеры булып эшләгән Михаил Юрьевич Жемков сайланды.

### Начальник билгеләнде

Норлат дәүләт орлык инспекциясе начальнигы итеп Замир Шамил улы Бильданов билгеләнде.

# 30 мартта районыбызда Татарстан Дәүләт Советына депутат сайлау булды

# НАМУС КУШКАНЧА

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

Без округ сайлау комиссиясе белән дә әледән әле элемтәгә кереп тордык. Тавыш бирү тәмамланырга берничә сәгать кала комиссия рәисе Нәбиулла Хәйруллович Абдуллин тавыш бирүнең барышында алай зур замечаниеләр юк, Әхмәт, Югары Норлат, Биккол, Зирекле, Кизләү, Кычытканлы, Яңа Әмзә, Иске Әлмәт, Колбай Мораса, Чулпан, Бутаиха сайлау участокларында тавыш бирү аеруча активлык белән бара диде. Өйләгә кадәр үк тавыш бирү ябык сайлау участогы - Октябрь үзәк район шифаханәсендә, соңрак - сигез авыл участогында тәгәлләнде. Көндезге 12 дә округ сайлау комиссияссе Татарстан Республикасы үзәк сайлау комиссиясенә 50 нче номерлы сайлау округында сайлаулар булды дип хәбәр бирде, чөнки бу вакытка инде сайлаучыларның 50 проценттан артыгы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар турында»гы Законының 33 маддәсендә билгеләнгәннән 15 процентка күбрәк кеше тавыш бирергә өлгергән инде. 14.00 сәгатьтә районда исемлеккә кертелгән сайлаучыларның 70 проценты, 18 сәгатькә - 80,3 проценты тавыш бирде.

Тавыш бирү 21 сәгатькә кадәр дәвам итте.

**Т.НАЗАРОВА.**

***

## БӘЙРӘМ РУХЫНДА

Киекле халкы сайлау участогына бәйрәмгә килгәндәй агылды. Тормыш мәшәкатьләре җилкәне басканда өлкән кешеләр мәдәният йортына да, мәктәпкә дә еш килә алмыйлар шул. Ә менә бу юлы мәктәптәге сайлау участогына җыелгач, берочтан рәхәтләнеп аралаштылар, сөйләштеләр дә алар. Фойеда эшләүче дүрт сәүдә ноктасы халыкка киң ассортиментта азык - төлек продуктлары, яшелчә, җиләк - җимеш тәкъдим итте. Соңрак район үзәгеннән концерт бригадасы килеп төште. Киеклелеләр районыбызның моңлы сандугачы Сания Котдусованың җырлавын, Әлфирә Җәлалованың биюен, Гөлсинә һәм Сабит Минехановларның һәм башкаларның чыгышларын җылы кабул иттеләр.

Тавыш бирү зур оешканлык белән барды.

- Халкыбыз бик актив булды. Аякларында йөри алырлык карт - карчыкларны гадәттәгечә өйләренә барып сайлатмадык. Аларны участокка алып килү өчен ассоциация рәисе Н.Шәрәпов машинасын бирде. Алар да бәйрәм рухын тойсыннар, бөтен кеше белән бергә катнашсыннар, күңел ачсыннар дидек,- диде безгә сайлау участогы рәисе Й.Х.Садыйков.

## АКТИВЛЫК БЕЛӘН

Иске Әмзә халкы быелгы сайлауларда аеруча актив булды. Беренче булып сайлау участогына килеп, бюллетеньне ящикка салган алдынгы комбайнчы Илгиз Шәйдуллинның аягы җиңел булды: төш вакытына сайлаучылар исемлегенә кертелгән 213 кешенең 200се гражданлык бурычларын үтәгәннәр иде инде.

Сайлау участогында да көне буе җанлылык хөкем сөрде: музыка тынмады, фойеда халыкка хезмәт күрсәтелде. Шуңа халыкның кәефе дә көр, бәйрәмчә иде.

**Р.ГИНЯЕВА.**

# Рухи савыгу юлында



# КҮМӘК ЭШТӘН ТУГАН ИЗГЕ ЙОРТ

***Инде хәбәр иткәнебезчә, 28 мартта Норлатта православие чиркәве ачылды. Башта гади гыйбадәт йорты ачудан башланып, 1993 елда Илья чиркәвенең беренче нигез ташы салуга киткән изге эш шулай итеп нәтиҗәле тәгәлләнде.***



Чиркәү кыңгыравы чыңы ул көнне йөзләрчә халыкны үз тирәсенә җыйды. Тантанага килгәннәргә иң элек район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин кыскача сүз белән мөрәҗәгать итте. Районның рухи тормышындагы бу истәлекле вакыйга белән котлап, ул нинди милләттән булуларына карамастан, бар кешене дә тату эшләү һәм яшәү уе берләштерергә тиеш, чөнки дин элек - электән кешеләрнең рухи - әхлакый кризистан котылырга омтылуына булышлык итеп килгән, дигән теләк белдерде.

Аннары Алла йортының символик ачкычын кабул итеп, Казан һәм Татарстан протиерие Анастасий атакай вәкиле Сильвестр атакай чыгыш ясады. Ул чиркәү төзелешенә саллы һәм төп өлеш керткән район җитәкчесенә рәхмәт белдерде һәм зиннәтле гыйбадәт йортлары салу гына аз, андый храмны һәркемнең үз күңелендә дә коруы кирәк, балаларыбызда да дингә ышану һәм хөрмәт уяту зарур диде.

Чиркәү төзелешенә җитәкчелек иткән Василий Семенович Филлиппов, дистәләрчә ел гомерен мөгаллимлек һәм мәгърифәтчелек эшенә багышлаган Василий Ермолаевич Поселенов, пенсионер Вера Федоровна Сальцина да тантанада дулкынлану белән һәм йөрәкләргә үтәрлек сүзләр белән сөйләделәр. Норлатлы Валерий Николаевич Кузнецов, төзелешнең генераль подрядчысы - 53 нче СМУның хәзерге башлыгы Ирек Ядьгәрович Гайнанов та барлык диндарларны Илья чиркәве ачылу тантанасы белән котладылар. Норлат үзидарә Советы рәисе Ф.И.Гайнуллин, бу вакыйганың татулык һәм килешү елына туры килүен билгеләп, чиркәү төзелешенә зур гамәли өлеш керткән «Норлат - Октябрь ит комбинаты», «Норлат шикәр заводы», НГДУ, «Норлат - Октябрь элеваторы», «Норлатнефтепродукт», «127 нче ПМК» акционерлык җәмгыятьләре, Синдряков исемендәге КФХА, Норлат геологик разведка идарәсе, Норлат автоюллар идарәсе, район элемтә бүлеге, шәһәр электр челтәре, МПП һәм башка коллективларны билгеләп үтте.

Традицион ал тасманы кисү хокукы Сильвестр атакайга бирелде. Аннан яңа чиркәүдә беренче гыйбадәт укылды.

Шул ук көнне чиркәүгә акчалата һәм әйберләтә бүләкләр дә тапшырылды.

Озакламый бу чиркәү гыйбадәт йортының барлык таләпләренә туры китереп җиһазланачак һәм күңелләрендә изге хис, олы ышаныч йөрткән һәркем биргә килеп рухын, күңелен савыктыра алачак.

**Т.НАЗАРОВА.**
**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

# Коллегалар кунакка килде

Узган атнада мөхәррир Р.К.Хәбибуллина җитәкчелегендә Аксубай районының «Авыл таңнары» газетасы редакциясеннән бер төркем коллегаларыбыз бездә кунакта булып киттеләр. Күршеләребез визитының төп максаты - газета чыгаруны компьютерлаштыру, яңа шартларда эшне оештыру белән танышу иде. Аксубайлылар әле аңа күчүгә әзерлек чорын гына башлыйлар, шуңа алар безнең инде көйләнгән технологиягә кызыксынып та, бераз көнләшеп тә карадылар. Әлбәттә, иҗат коллективларының үз традицияләре, иҗади эшчәнлеге мәсьәләсендә дә уртаклашыр сүзләре байтак иде. Озакка сузылмаган бу очрашу - аралашу дустанә атмосферада, файдалы һәм кызыклы булды.

## Күренекле якташларыбыз

# Аның тормышы - батырлык

Мин гомерем буена ихтыяр көче зур булган кешеләргә сокланып яшим. Андый кешеләр безнең авылда да бик күп. Шуларның берсе - Нил Нурулла улы Гатин.

Нил Гатин 1935 елның 21 июнендә Октябрь районының Колбай Мораса авылында укытучы гаиләсендә туа. Авыл мәктәбендә 9 нчы классны бетергәч, язмыш аны урын өстенә ятарга мәҗбүр итә. Буыннарына каты салкын тию аркасында, ул айлар буе урын өстендә ята. Гаиләдә алар 7 бала үскәннәр. Авыр еллар, ачлык булуга да карамастан, булган һәр буш минутын әнисе Галия апа улы Нилгә багышлаган. Ул Нил абыйның буыннарын дәвалау өчен халык медицинасыннан төрле чаралар кулана. Солыны пешереп буыннар өстенә ябып тота, һәртөрле ванналар ясый. Шулай итеп, рәхимсез авыру чигенә башлый, ана кеше газиз баласын аякка бастыра. Нил абый үзе дә, җайлана башлагач, бер дә тик ятмый, үз өстендә эшли башлый.

Урта мәктәпне тәмамлагач, Казанның авыл хуҗалыгы институтына керә һәм 1954 елның сентябрь аенда йөгерү күнегүләре ясый башлый. Шулай итеп, Нил абый, барлык авырлыкларны җиңеп, тормышта үзенең дөрес юлын, спортның йөгерү төрен сайлап ала. 10 - 20 км. йөгерүдә Татарстанның беренче рекордчысы титулын ала.

Ул 1959 елда КАХИны, ә 1967 елда Мәскәү шәһәренең Дәүләт үзәк физкультура институтын (ГЦОЛИФК) тәмамлый.

Нил абый «Спартак», «Динамо» спорт җәмгыятьләрендә инструктор булып эшли. КАИда (Казанның Дәүләт техник университетында) физик тәрбия кафедрасында өлкән укытучы булып эшли, Казанда, Россиядә уздырылган конференцияләрдә катнашып методик эшләр яза, фән белән шөгыльләнә. Әмма спортны да ташламый.

5000, 10000 метрга йөгерү буенча күп мәртәбә Казан шәһәренең, Татарстанның чемпионы, экс - рекордчысы исемнәренә лаек була, төрле ярышларда уңышлы катнашканы өчен 105 Мактау кәгазе һәм дипломнар белән бүләкләнә. Нил абый 1971 елның 23 февралендә 60 километрны 4 сәгать 12 минут 29 секундта йөгереп, 35 яшьтән өлкән ирләр өчен иң яхшы вакытын күрсәтә, бу күрсәткеч хәзерге көндә дә яхшыртылмаган. Нил абый 42 ел эчендә барлыгы 258791 км. араны йөгереп узган, ягъни җир шарын экватор буенча алты мәртәбә әйләнеп чыккан.

Күптән түгел күренекле якташыбыз авылга кайтты. Г.Кариев музеенда кунакта булды. 62 яшендә булуына карамастан, ул бүген дә төз гәүдәле, шат күңелле, тулы энергияле, аның белән сөйләшеп утыру да яшәү көче бирә.

Нил абый музейга бик күп значокларын, Мактау кәгазьләрен, Казанда үткәрелгән тынычлык марафонында катнашкандагы 290 нчы номерын һәм башка бик күп истәлекле әйберләрен бүләк итте.

Колбай Мораса урта мәктәбендә «Батырлык атналыгы» барганда бу бүләкләрдән күргәзмә оештырдык, Нил Гатинның тормыш юлы турында сөйләдек. Чынлап торып уйласаң, аның тормыш юлы тулы бер батырлык бит.

**Г.САДРЕТДИНОВА,**
**музей хезмәткәре.**

## Авыл: кичә, бүген, иртәгә

# ХЕЗМӘТКӘ КАРАП КӨН КҮРСӘЛӘР...

## Мантыр мөмкинлек беткәч

***«Заря» крестьян - фермер хуҗалыклары ассоциациясенең һичкайчан үзен күрсәтә алганы булмады. Алай гына да түгел, ул барлык параметрлар буенча да ызандаш хуҗалыклардан артта сөйрәлде. Узган ел, мәсәлән, хуҗалык буенча һәр сыердан савылган сөт 2 мең килограммнан аз гына артты. Нәсел эшенә игътибар булмады. Такы - токы азык ашаган маллар үрчемәде, булганнары акрын үсте. Дуңгызчылык тармагының тамыры исә соңгы елларда бөтенләй корыды.***

***Зарялылар игенчелектә ирешелгән уңышлары белән дә әллә ни мактана алмадылар. Бөтен авыл белән кубып эшкәртелгән шикәр чөгендере гектардан 140 центнер гына уңыш бирде, рентабельлелеге түбән булды.***

***Гомумән, хуҗалык мантымады, продукция җитештерү артмады, аның әҗәте үсте, икътисадый хәле тотрыксызланды. 5 - 6 ай рәттән хезмәт хакы ала алмаган авыл эшчәннәренең дә кәефләре әллә ни күтәрелмәде. Кыскасы, кризис чиккә җитте.***

### Эшләгән генә ашый

Яңа рәис Ильяс Тәмаев шундый мирас белән кабул итте хуҗалыкны. Үз җиренә үзе хуҗа булып, керемнәрен дә, чыгымнарын да аерым санап, аерым хуҗалык булып яшәгән «Аргамак» фермер хуҗалыгы җитәкчесе, биредә эшли башлавының беренче көнендә үк, аның хуҗалык һәм икътисади мөмкинлекләрен өйрәнеп бер нәтиҗәгә килде: алга таба болай яшәп булмаячак. Һәм ул тупланган тәҗрибәсен «барлап», район делегациясе составында һәм шәхси инициативасы буенча республиканың алдынгы хуҗалыклары тәҗрибәсен өйрәнеп, «Заря» өчен хуҗалык итүнең яңа алымын макетлаштыруга керешә. Фикерләрен район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин да хуплагач, җиң сызганып эшкә керешә. Билгеле инде, авыл халкы күңелендә еллар буена ныгыган гомуми стереотипларны җиңеп, яңача эшләүгә өндәү җиңел бирелми. Аерым производство участокларында сөйләшүләр алып бару, крестьяннарны үз җирләрендә үзләре хуҗа булып эшләргә үгетләү, гомумән, эшләүче һәр кешенең күңеленә җитәргә омтылу - барысы да артта калды бүген. Хәзер Якушкино авылында яшәүче һәркем - крестьяннар, интеллигенция вәкилләре, пенсионерлар - җәмгысе 396 кеше үзләренә тиешле мөлкәт - җирләре белән учредительләр итеп расландылар. Җир пае өчен биреләсе икмәк, печән һәм башкалар - барысы да алынасы уңыш исәбеннән чыгып бүленәчәк дип вәгъдә ителде. Ә инде кооперативларга керергә каршы булучыларга, үз пайларын алып, мөстәкыйль эшләү мөмкинлеге дә аңлатылды. Әмма хуҗалыкта мондый юлны сайларга теләүче табылмады.

Хәзер «Заря» 5 аренда кооперативына бүленгән. Аларның эшенә 13 кешедән торган аренда кооперативлары Советы җитәкчелек итә. Совет рәисе итеп Ильяс Тәмаев сайланган. Уставта барлык кооперативларның да аңа тулысынча буйсынуы каралган.

Кооперативларның беренчесе - савым сыерлары асрау белән шөгыльләнүчесенә Ильяс Таһирович үзе җитәкчелек итсә, Евгений Яковлев бозаулар асрау кооперативы башлыгы итеп билгеләнгән. Дуңгызчылыкның үз хуҗасы - Владимир Акмурзин бар. Коллективларның тагын берсе - хезмәт күрсәтү кооперативы дип атала. Исәп - хисап алып баручылар, техникага хезмәт күрсәтүчеләр керә аңа. Бишенчесе - төзелеш кооперативы. Өч кооперативта төзү - ремонт эше таләп ителгәндә әлеге коллектив эшчеләрен яллый алалар.

Шунысын әйтергә кирәк, җитәкчеләрнең төп белгечлекләре терлекчелеккә кагылмаганлыктан, һәр кооперативка белгечләр дә кертелгән. Элеккеге ферма мөдире Вячеслав Ермошкин беренче, баш ветеринария табибы Жозефина Иштуллина икенче, баш зоотехник Леонид Акмурзин өченче звено составына кертеләләр. Учетчы, бригадир ише вазифа штат бирәмлегеннән бөтенләй төшерелеп калдырыла.

Барлык кооперативларга да гадел нигездә тигез күләмдә җир, техника бүлеп бирелә. Мисал өчен, аларның беренчесендә 12 савучы, 6 мал караучы, бер ферма мөдире эшли. Көпчәкле һәм чылбырлы 3әр трактор, 2 комбайннары бар, чөгендер казыту, азык җитештерү техникасы белән дә комплектланган кооператив. Җире исә 577 гектар тәшкил итә. Калган ике звеноның да җир мәйданнары шул чама. Үзеннән үзе аңлашыла: кооперативлар эшчәнлеге бер профильле генә түгел - күптармаклы булачак. Икенче төрле итеп әйткәндә, кооперативлар сөт, ит җитештерү өчен маллар да караячаклар, аларга азык хәзерләү максатында иген дә игәчәкләр, продукцияне үзләре сатачаклар да. Тулысынча хуҗалык исәбенә корылган, хезмәтнең ахыр нәтиҗәләренә турыдан - туры бәйле булган алым, чыгымнарга каршы механизмны хәрәкәткә китереп, кооператив членнарының аңлы хезмәтенә ирешүне күздә тота.

Ильяс Таһировичның үзе әйтүенчә, исәп - хисап безнең бабайлардагыча булачак: ягулык, ашлама, орлыкны үзләре табыштырып, аның чыгымнарын да үзләре күтәрәчәкләр. Кооператив әгъзаларын туплап эшкә билгеләү дә аның җитәкчесеннән торачак. «Кем эшләми, шул ашамый» дигән принцип буенча буласы көн кебек ачык аның. Ә инде эшче көч җитешмәгәндә аны яннан яллап эшләтү мөмкинлеге бар. Бу очракта чек системасы эшкә җигелә инде. Ә хезмәт хакы исәпләү юлы гадинең дә гадие: продукция никадәр күп җитештерелсә, хезмәт хакы да үсәчәк. Икенче төрле әйткәндә, хезмәтенә карап көн күрәчәк авыл кешесе.

### «Бабайларча яшәсәк кенә...»

- Билгеле инде, реформацияләүнең беренче адымнары җиңел булмаячак, хаталар да аз булмас,- ди Ильяс Таһирович. - Әмма авырлык белән булса да алга барырга кирәк, артка юл юк.

Аңлашыла ки, юл җиңел булмаячак. Алга адым никадәр генә камил булса да, алда телгә алынган мирас кара шәл булып озак барыр әле артларыннан. Хәзер хуҗалыктагы 230 баш савым сыеры арасында мул сөтле, нәселләре бармак белән генә санарлык. Ә савым көтүен алыштыру зур чыгымнар сорый. Бу эшне хуҗалыкның үзендә якын берничә ел эчендә башкарып чыгарга да өмет итеп булмый. Ильяс Таһирович хуҗалыкта асрала торган 120 баш танага зур өметләр баглый, кысан биналарда, такы - токы ризык белән асралган бу маллар быелгы кыштан салкын ысул белән бәйсез асрала башлаган. Кискен рәвештә артымнары да үскән аларның. Шулар арасыннан көтүне тулыландыру өчен 35 баш мал аерым сайлап алынган. Әле тагын 30лап баш нәселле тана кирәк. Әлеге проблеманы хәл итү юлын табалар кебек биредә. Булган барлык таналарны каплатып һәм бозаулатып, аз сөтле сыерларны саумыйча бозауларын имезеп үстерергә планлаштырыла. Ильяс Таһирович әйтүенчә, мондый сыерларны савып тору - вакытны бушка әрәм итү генә, ә имезеп үстерелгән бозау бер ел эчендә 420 - 430 килограммга җитәргә сәләтле икән. Андый мал иткә тапшырсаң да йөз кызартмый, имеп үскән бозаудан яхшы сыер да чыга.

Элегрәк хуҗалыктагы 625 баш мөгезле эре терлекне 62 кеше караган, киләчәктә исә шуның 30 проценты гына хезмәт күрсәтәчәк малларга. Кооперативлар Советы рәисе «кыскартылган» халык өчен яңа эш урыннары булдыру максатында савым сыерларының баш санын 350 - 400гә җиткерергә исәпли.

Дуңгызчылыкны торгызуга да йөз тотыла. Шул максатта быел 30 баш ана дуңгыз сатып алынган инде. Июнь аенда алыначак үрчем - киләчәктә дуңгызларның баш санын арттыруда алга бер адым булачак.

Салкын ысул белән бәйләмичә асрау күзлегеннән чыгып барлык терлекчелек биналарына реконструкция ясау да планда. Тәҗрибә күрсәткәнчә, малларны салкында асрау үзен аклый. Мисал өчен февраль аенда профилакторийда асралган 8 баш бозау үлгән. Соңгы айда туган бер бозау салкынга чыгарыла башлагач үлем - китем туктаган. Малларны салкында асрау өчен сөт блогы төзеп, УДС - 3 саву җайланмалары гына куясы кала. Реконструкцияләнгән биналарда тирес чыгару транспортерлары да булмаячак, электр энергиясе чыгымнарын киметү максатында яктырткычлар санын да минимумга кадәр киметү каралган. Ахыр чиктә боларның һәркайсы чыгымнарга каршы механизмны тулы көченә хәрәкәт иттерергә ярдәм итәчәк.

Игенчелекне дә аграр үзгәрешләр көтә. Быел «Заря»да сабан бодае мәйданнарын 600 гектарга җиткерү күздә тотыла. Бөртек өчен кукуруз чәчеп тә зур керем алырга исәплиләр биредә. Аның һәр гектарыннан 50 - 60 центнер уңыш җыеп алсалар максатларына ирешкән дип санарга нигез бар. Яңача эшләү азык культуралары игүгә дә башкача карауны таләп итә. Аларның нәкъ яртысын күпьеллык үләннәр алып торачак.

Әлеге мәйданнарның 80 процентында аксымга бай люцерна чәчәргә исәплиләр. Бу культураның һәр гектарыннан аз дигәндә 50 - 60 центнер коры печән, 250 - 300 центнер яшел масса җыеп алу - маллардан продукция алуны сизелерлек арттырырга ярдәм итәчәк. Икенчедән, люцерна башка культуралар өчен дә яхшы элгәр булып тора.

Шуның өстенә люцерна орлыгын үзләрендә хәзерләү максатында быел киң рәтле чәчкечләр ярдәмендә 20 гектарда люцерна чәчәргә исәплиләр.

Шикәр чөгендеренә дә игътибар артачак. Чәчү әйләнеше структурасын үтәү максатында быел бу культураны һәр өч звено да игәчәк. Аның һәр гектарыннан уртача 280 - 300 центнер уңыш җыю максат ителә.

- Барысын да эшләрбез, кыенлыкларны ерып чыгарбыз, тик гадел сәясәт алып барыгыз, дөрес эшләргә ярдәм итегез,- диләр авыл эшчәннәре үзләре.

- Авыл эшчәннәренә якты өмет белән карыйбыз, ә авылны үзгәртеп кору эшен өр - яңадан башламасак, авылның бөлгенлеккә төшүенә юл куймаслык чаралар күрмәсәк, хәлне төзәтү үтә кыен булачак,- ди И.Тәмаев та.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## КУЛЛАРЫННАН КУАННАР

Ерепкинода Яковлевлар белән мине бригадир Анатолий Соловьев таныштырды. Гаилә башлыгы Петр Ивановичның кулыннан һәр эш килә, диде ул: столяр да, балта остасы да, чәчүче дә, мал карауның да рәтен белә... Ә хатыны Валентина Дмитриевна чәчү вакытында, урак өстендә кырдагыларны тәмле ашлары белән сыйлый. Анысы әле әнисеннән тагын чыккан буыннарны утырту хикмәтләренә дә өйрәнгән... Әнә шунысы миндә аеруча кызыксыну уятты...

Йортта безне ачык йөзле хуҗабикә каршы алды. Бер - ике авыз сүз алышуга, мин үземнең гозеремне сөйләп бирдем: армиядә чакта ук минем умыртка баганам ике төштән сынган иде. Валентина Дмитриевна шуны карый алмас микән? Ул тиз генә сабынлады, җылы су әзерләде дә эшкә керешә. Бер унлап минут узгач, аннан тагын шулкадәр... Ул арада авыртуымның серен ачыклады һәм, ни хикмәт, авырту басыла төшкәндәй булды. «Инде авырткан төшләрне һичшиксез массажларга кирәк, физзарядка ясагыз - һәм бөтенесе дә унайга китәр», - дип өметләндерде мине «табиб».

Үзендәге бу сәләтне Валентина Дмитриевна бала чагында ук тойган. Шуннан бирле ул шифалы куллары белән йөзләрчә кешене савыктырган инде - төгәл генә санын кем санап барган соң аның. Әле бит колхоз эшеннән кала йортында да мәшәкать җитәрлек Валентина Дмитриевнага: каралтыларында сыер һәм үгез, сарык һәм дуңгыз тоталар, бакчаларында күп төрле җимеш агачлары... Өч бала үстергәннәр Яковлевлар, инде һәркайсы башлы - күзле булганнар.

Валя әби өендә бөтерчек кебек - бер генә дә тик утырганын күрмәссең. «Сәгать 5тән торабыз, төнге уннарга кадәр гел аяк өстендә».

Әйе, гомерен йоклап үткәргән кешегә бәхет тәтеми шул инде ул.

**В.КОМОЛОВ.**

